Республика Татарстан
**СОВЕТ ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА ДЖАЛИЛЬ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Ахмадиева, д.26, п. Джалиль, 423368
Телефон: (85559) 31-0-97, 60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

Татарстан Республикасы
**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ҖӘЛИЛ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫ ПОСЕЛОК СОВЕТЫ**

Ахмадиев урамы, 26 йорт, Җәлил поселогы,423368
Телефон: (85559 ) 31-0-97,60-2-20, факс: 31-0-97
E-mail: POSSOVETD@mail.ru

ОГРН 1021601312501 ИНН/КПП 1636001410/163601001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
21.11. 2016 ел № 40

**Җир кишәрлегеннән рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы «Җәлил шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы, 2016 елның 15 ноябрендагы гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә һәм гавами тыңлаулар уздыру буенча эшче төркем тәкъдимнәре нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. 16:36:2003:200 кадастр номеры белән Сарман муниципаль районы, Җәлил поселогы, Новая урамы, 17а йорт адресы буенча урнашкан, гомуми мәйданы 41 кв.м. булган җир кишәрлеген «Шәхси торак төзелеше өчен», «Автотранспортка хезмәт күрсәтү өчен» категорияләреннән файдаланырга рөхсәт ителә.

2. Җир кишәрлегенең кадастр паспортына тиешле үзгәрешләр кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасына мөрәҗәгать итәргә.

3. Җир кишәрлегенә хокук билгели торган документларга тиешле үзгәрешләр кертү өчен, Федераль теркәү хезмәтенең Сарман муниципаль районы идарәсенә мөрәҗәгать итәргә.

4. Әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән рөхсәт ителгән куллану төре нигезендә җир кишәрлегеннән файдалануны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә һәм Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Җәлил шәһәр тибындагы поселогы башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Җәлил шәһәр тибындагы поселогы
Советы Рәисе Л.М.Бадиков